ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Җир асты байлыклары турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 11 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 4, № 5, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяда:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасында катнашу;»;

б) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка, шулай ук гомумтаралган файдалы казылмалар запасларына һәм эчәргә яраклы сулар белән тәэмин итү яисә техник сулар белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб метрдан артмаган җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы үткәрү;»;

2) 13 статьяның дүртенче өлешендә «16 статьясындагы унҗиденче абзацы нигезендә» сүзләрен «16 статьясындагы унсигезенче абзацы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 14 статьяда:

а) беренче өлештә:

өченче абзацта «шулай ук углеводород чималын разведкалау һәм чыгару очрагында тау токымнары катламнарында ияреп чыгучы суларны һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үзләренең җитештерү, технологик ихтыяҗлары өчен файдаланган суларны урнаштыру» сүзләрен «ияреп чыгучы суларны һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучылар углеводород чималын разведкалаганда һәм чыгарганда үзләренең җитештерү, технологик ихтыяҗлары өчен файдаланган суларны тау токымнары катламнарында урнаштыру, калий һәм магний тозларын разведкалауны һәм чыгаруны, шулай ук беренчел эшкәртүне гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучыларда барлыкка килә торган суларны тау токымнары катламнарында урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү.»;

б) түбәндәге эчтәлекле өченче өлеш өстәргә:

«Җир асты байлыклары шулай ук авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү һәм мондый файдалы казылмаларны разведкалау һәм чыгару өчен дә бер үк вакытта файдалануга бирелергә мөмкин. Үзләренә карата җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү өчен бирелергә мөмкин булган авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларның төрләре федераль законнар нигезендә билгеләнә.»;

4) 15 статьяда:

а) икенче өлештә:

алтынчы абзацта «16 статьясындагы унҗиденче абзацы нигезендә» сүзләрен «16 статьясындагы унсигезенче абзацы нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«7 елга кадәр – авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү өчен «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $10^1$ статьясындагы 3 пунктының сигезенче абзацы нигезендә, 15 елга кадәр – авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү өчен «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $10^1$ статьясындагы $4^1$ пункты нигезендә.»;

б) өченче өлештә «углеводород чималын разведкалаганда һәм чыгарганда тау токымнары катламнарында ияреп чыгучы суларны һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үзләренең җитештерү, технологик ихтыяҗлары өчен файдаланган суларны урнаштыру өчен, шулай ук» сүзләрен «ияреп чыгучы суларны, җир асты байлыкларыннан файдаланучылар углеводород чималын

разведкалаганда һәм чыгарганда үзләренең җитештерү һәм технологик ихтыяҗлары өчен файдаланган суларны, калий һәм магний тозларын разведкалауны һәм чыгаруны, шулай ук беренчел эшкәртүне гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучыларда барлыкка килә торган суларны тау токымнары катламнарында урнаштыру өчен,» сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмләләр өстәргә: «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $10^{1}$ статьясындагы 3 пунктындагы сигезенче абзацы нигезендә файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлегендә авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү срогы, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләп бетерү кирәк булган очракта, җир асты байлыкларыннан файдаланучы инициативасы белән бер тапкыр 3 елга кадәр озайтыла. «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $10^{1}$ статьясындагы $4^{1}$ пункты нигезендә файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлегендә авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү срогы җир асты байлыкларыннан файдаланучы инициативасы белән, озайтулар саны чикләнмичә, 5 елга кадәр озайтыла.»;

5) 16 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче абзац өстәргә:

«авыр чыгарыла торган файдалы казылмалары булган һәм авыр чыгарыла торганга керми торган дәүләт файдалы казылмалар запаслары балансында исәпкә алынган шул ук төрдәге башка файдалы казылмалары булмаган җир асты байлыклары кишәрлегендә мондый файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү өчен җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү турында конкурс комиссиясе карары;»;

б) бишенче – җиденче абзацларны тиешенчә алтынчы – сигезенче абзацлар дип санарга;

в) сигезенче абзацны тугызынчы абзац дип санарга һәм анда «Продукция бүлешү турындагы килешүләр хакында» Федераль закон нигезендә» сүзләрен «Продукция бүлешү турындагы килешүләр хакында» 1995 елның 30 декабрендәге 225-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

г) тугызынчы – унбишенче абзацларны тиешенчә унынчы – уналтынчы абзацлар дип санарга;

д) уналтынчы абзацны унҗиденче абзац дип санарга һәм анда «суларын чыгару өчен» сүзләрен «суларын разведкалау һәм чыгару өчен» сүзләренә, «табу һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү, аларны чыгару» сүзләрен «эзләү һәм бәяләү, аларны разведкалау һәм чыгару максатларында геологик өйрәнү» сүзләренә алмаштырырга;

е) унҗиденче абзацны унсигезенче абзац дип санарга;

ж) унсигезенче абзацны унтугызынчы абзац дип санарга һәм анда «хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү» сүзләрен «эчәргә яраклы сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү (алга таба – эчәргә яраклы сулар белән тәэмин итү) яисә техник сулар белән тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

6) 18 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү барышында мондый файдалы казылмаларны авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләүгә «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының $23^2$ статьясында каралган тәртиптә килештерелгән һәм расланган проект документациясе нигезендә билгеләнгән күләмнәрдә чыгарырга.»;

7) 19 статьяның беренче өлешендәге megaундүртенче абзацында «һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үзләренең җитештерү, технологик ихтыяҗлары өчен файдаланган суларны» сүзләрен «, җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үзләренең җитештерү, технологик ихтыяҗлары өчен файдаланган суларны, калий һәм магний тозларын разведкалауны һәм чыгаруны, шулай ук беренчел эшкәртүне гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучыларда барлыкка килә торган суларны» сүзләренә алмаштырырга;

8) 24 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24 статья. **Җир асты байлыкларын файдалы казылмаларны чыгару, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү, махсус саклана торган геологик объектлар булдыру өчен, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү өчен, шулай ук минерал чималны разведкалаганда һәм чыгарганда продукцияне бүлешү турында килешү нигезендә тапшыру**»;

б) беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Файдалы казылмаларны чыгару, файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү, махсус сакланылучы геологик объектлар булдыру өчен, авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү өчен җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия нигезендә, шулай ук минерал чималны разведкалаганда һәм чыгарганда продукцияне бүлешү турында килешү нигезендә җир асты кишәрлеге файдаланучыга тау эшләре кишәрлеге рәвешендә тапшырыла.»;

9) $35^1$ статьяның икенче өлешендәге сигезенче абзацында «хуҗалык-көнкүреш суы» сүзләрен «эчәргә яраклы сулар яисә техник сулар» сүзләренә алмаштырырга;

10) $35^{8.2}$ статьяда:

а) исемендә «хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү максатларында» сүзләрен «эчәргә яраклы сулар яисә техник сулар белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен» сүзләренә алмаштырырга;

б) беренче өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бакчачылык коммерциягә карамаган ширкәтләрен һәм (яисә) яшелчәчелек коммерциягә карамаган ширкәтләрен эчәргә яраклы сулар яисә техник сулар белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган җир асты суларын чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү өчен әлеге Законның $35^2$ статьясындагы икенче – бишенче өлешләрендә каралган документлар, шулай ук түбәндәгеләр дә кирәк:»;

11) 73 статьяда:

а) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы үткәрү, җир асты байлыкларын, файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләрен геологик өйрәнү эшләрен һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләрне дәүләт исәбенә алу;»;

б) тугызынчы абзацта «һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үзләренең җитештерү, технологик ихтыяҗлары өчен файдаланган суларны» сүзләрен «, җир асты байлыкларыннан файдаланучыларның үзләренең җитештерү, технологик ихтыяҗлары өчен файдаланган суларны, калий һәм магний тозларын разведкалауны һәм чыгаруны, шулай ук беренчел эшкәртүне гамәлгә ашыручы җир асты байлыкларыннан файдаланучыларда барлыкка килә торган суларны» сүзләренә алмаштырырга;

в) уникенче абзацта «һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү (алга таба – эчәр сулар белән тәэмин итү) яисә сәнәгать объектларын йә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү» сүзләрен «белән тәэмин итү яисә техник сулар белән тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга;

12) 75 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«75 статья. **Дәүләт исәбенә алу һәм дәүләт теркәве**

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен дәүләт исәбенә алу җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләре дәүләт реестрын алып бару юлы белән гамәлгә ашырыла. Файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләрен һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләрне дәүләт исәбенә алу файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләре һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияләр дәүләт реестрын алып бару юлы белән башкарыла.

Әлеге статьяның беренче өлешендә күрсәтелгән дәүләт исәбенә алу һәм дәүләт реестрларын алып бару җир асты байлыкларының дәүләт фондына идарә

итүнең федераль органы билгеләгән тәртиптә бердәм система буенча гамәлгә ашырыла.»;

13) 84 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«84 статья. **Файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы**

Файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запаслары, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүмат дәүләт экспертизасы узарга тиеш, моңа эчәргә яраклы сулар яисә техник сулар белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм аларны чыгару күләме тәүлегенә 100 куб метрдан артмаган җир асты суларын чыгару өчен бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләрендәге җир асты сулары запаслары, шулай ук авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү барышында чыгарыла торган авыр чыгарыла торган файдалы казылмалар запаслары керми.

Файдалы казылмаларны һәм җир асты суларын чыгару аларның запасларына дәүләт экспертизасы үткәрелгәннән соң гына рөхсәт ителә, моңа эчәргә яраклы сулар яисә техник сулар белән тәэмин итү максатларында файдаланыла торган һәм аларны чыгару күләме тәүлегенә 100 куб метрдан артмаган җир асты суларын чыгару керми, шулай ук авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү барышында чыгарыла торган авыр чыгарыла торган файдалы казылмалар чыгару керми.

Файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасы үткәрү нәтиҗәләре файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына дәүләт экспертизасының бәяләмәсе белән рәсмиләштерелә, ул аларны федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт балансына кую өчен нигез булып тора.

Файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен яраклы җир асты байлыклары кишәрлекләре турында геологик мәгълүмат та дәүләт экспертизасы узарга тиеш. Мондый җир асты байлыклары кишәрлекләрен файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм аларны эксплуатацияләү өчен файдалануга бирү геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы үткәрелгәннән соң гына рөхсәт ителә, аның нәтиҗәләре файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасының бәяләмәсе белән рәсмиләштерелә.

Файдалы казылмалар һәм җир асты сулары запасларына, файдалануга бирелә торган җир асты байлыклары кишәрлекләре турындагы геологик мәгълүматка дәүләт экспертизасы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.»;

14) 86 статьяның өченче өлешендә «яисә сәнәгать объектларын йә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны су белән технологик тәэмин итү» сүзләрен «яисә техник сулар белән тәэмин итү» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 04 июль
№ 36-ТРЗ